КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 13 май г.Казань № 587

2024 – 2026 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү фаразын эшләү графигын раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, «Татарстан Республикасында стратегик планлаштыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 12-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2024 – 2026 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү фаразын эшләү графигын (алга таба шул ук эзлеклелектә – Фараз, График) расларга.

2. Республика башкарма хакимият органнарына График нигезендә үз юнәлешләре буенча фараз күрсәткечләрен бирүне һәм «Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше» дәүләт мәгълүмат-аналитика системасына (алга таба – Система) кертүне тәэмин итәргә.

3. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарына, Татарстан Республикасының муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына, Татарстан Республикасында үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларга республика башкарма хакимият органнарының рәсми сораулары буенча Фаразны эшләү өчен кирәкле мәгълүматны билгеләнгән тәртиптә җибәрүне;

Татарстан Республикасының муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына Графикта билгеләнгән сроклар нигезендә Системага фараз күрсәткечләрен кертүне гамәлгә ашыруны;

Татарстан Республикасында үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларга фараз күрсәткечләрен Системага кертүне гамәлгә ашыруны.

4. Республика башкарма хакимият органнары тарафыннан рәсми сораулар җибәрелгәндә һәм мәгълүмат бирелгәндә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән мәгълүматны саклау режимы тәэмин ителергә тиеш дип билгеләргә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 13 май, 587 нче
карары белән расланды

# 2024 – 2026 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү фаразын эшләү графигы

| Т/с | Материаллар һәм документлар, чаралар исеме | Җаваплы башкаручы | Тапшыру вакыты | Кайсы оешмага тапшырылуы |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| I. Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгына кертү өчен Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Уртача вакытка исәпләнгән чорга Россия Федерациясен социаль-икътисадый үстерү фаразын эшләү, аңа төзәтмәләр кертү, аның мониторингын гамәлгә ашыру һәм аны тикшерүдә тоту тәртибе һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең аерым актлары үз көчен югалткан дип тану турында» 2015 ел, 14 ноябрь, 1234 нче карары нигезендә 2024 – 2026 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү фаразын эшләү | | | | |
| 1. | 2024 – 2026 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү фаразы, шул исәптән тиешле исәп-хисаплар, нигезләүләр һәм аңлатма язуы белән вариант нигезендә Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының 2019 елның 13 мартындагы 124 номерлы боерыгы белән расланган урта сроклы чорга Россия Федерациясен социаль-икътисадый үстерү фаразын эшләү өчен Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары тарафыннан Россия Федерациясенең Икътисадый үсеш министрлыгына кертелә торган төп күрсәткечләр буенча тәкъдим ителә торган форма бүлекләре буенча: | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татар- | 2023 елның 23 июне – якынча<br><br>2023 елның 23 октябре – төгәлләштерелгән | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, «Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше» дәүләт мәгълүмат-аналитика системасы (алга таба – Система) |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | стан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Экология һәм табигать байлыклары министрлыгы, Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты | | |
| 1.1. | Халык | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | 2023 елның 23 июне – якынча<br><br>2023 елның 23 октябре – төгәлләштерелгән | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Система |
| 1.2. | Сәнәгать җитештерүе:<br>төяп җибәрелгән продукция (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) күләме, сәнәгать җитештерүе индексы, дефлятор индекс – Татарстан Республикасы буенча, шул исәптән икътисадый эшчәнлек төрләре буенча барлыгы;<br>продукциянең иң төп төрләрен табигый рәвештә җитештерү (шул исәптән оешмалар яктылыгында) | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы | 2023 елның 23 июне – якынча<br><br>2023 елның 23 октябре – төгәлләштерелгән | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Система |
| 1.2.1. | Төяп җибәрелгән продукция (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) күләме, сәнәгать җитештерүе индексы, икътисадый эшчәнлек төрләре буенча дефлятор индексы:<br>башка файдалы казылмаларны чыгару;<br>пар белән тәэмин итү; һаваны кондицияләштерү;<br>су белән тәэмин итү; су чыгару, калдыклар җыюны һәм утилизацияләүне оештыру, пычракларны бетерү эшчәнлеге | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасы Экология һәм табигать байлыклары министрлыгы | 2023 елның 15 июне – якынча<br><br>2023 елның 16 октябре – төгәлләштерелгән | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Система |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | металл булмаган башка минераль продукция җитештерү | | | |
| 1.2.2. | «Азык-төлек продуктлары җитештерү» икътисадый эшчәнлек төре буенча төяп җибәрелгән продукция (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) күләме, сәнәгать җитештерүе индексы, дефлятор индексы;<br>продукциянең иң төп төрләрен табигый рәвештә җитештерү | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | 2023 елның 15 июне – якынча<br><br>2023 елның 16 октябре – төгәлләштерелгән | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Система |
| 1.2.3. | «Компьютерлар, электрон һәм оптик эшләнмәләр җитештерү» икътисадый эшчәнлек төре буенча төяп җибәрелгән продукция (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) күләме, сәнәгать җитештерүе индексы, дефлятор индексы | Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы | 2023 елның 15 июне – якынча<br><br>2023 елның 16 октябре – төгәлләштерелгән | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Система |
| 1.3. | Электр энергиясенә тарифлар | Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты | 2023 елның 23 июне – якынча<br><br>2023 елның 23 октябре – төгәлләштерелгән | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Система |
| 1.4. | Авыл хуҗалыгы | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | 2023 елның 23 июне – якынча<br><br>2023 елның 23 октябре – төгәлләштерелгән | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Система |
| 1.5. | Төзелеш | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы | 2023 елның 23 июне – якынча<br><br>2023 елның 23 октябре – төгәлләштерелгән | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Система |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 1.6. | Транспорт | Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы | 2023 елның 23 июне – якынча<br><br>2023 елның 23 октябре – төгәлләштерелгән | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Система |
| 1.7. | Элемтә | Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы | 2023 елның 23 июне – якынча<br><br>2023 елның 23 октябре – төгәлләштерелгән | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Система |
| 1.8. | Сәүдә һәм халыкка хезмәт күрсәтү | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы | 2023 елның 23 июне – якынча<br><br>2023 елның 23 октябре – төгәлләштерелгән | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Система |
| 1.9. | Тышкы икътисадый эшчәнлек | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы | 2023 елның 23 июне – якынча<br><br>2023 елның 23 октябре – төгәлләштерелгән | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Система |
| 1.10. | Берләштерелгән бюджет | Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы | 2023 елның 23 июне – якынча<br><br>2023 елның 23 октябре – төгәлләштерелгән | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Система |
| 1.11. | Халыкның акчалата керемнәре:<br>халыкның җан башына уртача яшәү минимумы, шул исәптән халыкның төп социаль-демографик | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау | 2023 елның 23 июне – якынча | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Система |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | төркемнәре буенча:<br>хезмәткә сәләтле халык;<br>пенсионерлар;<br>балалар | министрлыгы | 2023 елның<br>23 октябре –<br>төгәлләштерелгән | |
| 1.12. | Хезмәт һәм халыкның эш белән тәэмин ителеше | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | 2023 елның 23 июне – якынча<br><br>2023 елның<br>23 октябре –<br>төгәлләштерелгән | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Система |
| 1.13. | 2024 – 2026 елларга ведомство буйсынуындагы оешмалар эшчәнлегенең төп күрсәткечләре фаразы | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы | 2023 елның 15 июне | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Система |
| 2. | Аңлатма язуы белән 2024 – 2024 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү фаразы | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы | 2023 елның 5 июле – якынча<br><br>2023 елның<br>10 ноябре –<br>төгәлләштерелгән | Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы, «Идарә» дәүләт автоматлаштырылган мәгълүмат системасы |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| II. Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштыру өчен 2024 – 2026 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү фаразының төп параметрларын эшләү | | | | |
| 1. | Муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары һәм оешмалары вәкилләре катнашында Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү фаразларын формалаштыру буенча ведомствоара эшче төркем утырышларын үткәрү | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы (килешү буенча), муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 2023 елның июне | |
| 2. | Тиешле исәп-хисаплар, нигезләүләр һәм аңлатма язуы белән 2024 – 2026 елларга Татарстан Республикасының шәһәр округларын, муниципаль районнарын һәм җирлекләрен социаль-икътисадый үстерү фаразлары | муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 2023 елның 23 июне | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Система |
| 3. | 2022 – 2024 елларга Татарстан Республикасы буенча фараз күрсәткечләре, 2023 елгы бәя, 2022 ел өчен факттагы күрсәткечләр, шул исәптән:<br>тулаем төбәк продукты күләме, узган ел дәрәҗәсенә карата динамика;<br>инфляция дәрәҗәсе;<br>төяп җибәрелгән продукция (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) күләме, сәнәгать җитештерүе индексы;<br>«төзелеш» эшчәнлек төре буенча башкарылган эшләр күләме, узган ел дәрәҗәсенә карата динамика;<br>авыл хуҗалыгы продукциясе күләме, узган ел дәрәҗәсенә карата динамика;<br>продукциянең төп төрләрен җитештерү күләме;<br>бухгалтерлык исәбе максатлары өчен оешмалар | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы | 2023 елның 5 июле | Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | табышы;<br>төп капиталга инвестицияләр күләме, узган ел дәрәҗәсенә карата динамика;<br>ваклап сату әйләнеше, узган ел дәрәҗәсенә карата динамика;<br>халыкка түләүле хезмәтләр күрсәтү күләме, узган ел дәрәҗәсенә карата динамика;<br>сумның АКШ долларына курсы;<br>«Юралс» маркасындагы чи нефтькә бәя;<br>хезмәт хакы фонды, узган ел дәрәҗәсенә карата динамика;<br><br>уртача хезмәт хакы, узган ел дәрәҗәсенә карата динамика;<br>җан башына исәпләгәндә яшәү минимумы күләме;<br>теркәлгән эшсезләр саны (чор ахырына);<br>теркәлгән эшсезлек дәрәҗәсе (чор ахырына) | | | |
| 4. | 2024 – 2026 елларга фараз күрсәткечләре, 2023 елгы бәя, муниципаль районнар һәм шәһәр округлары яктылыгында 2022 елга факттагы күрсәткечләр, шул исәптән:<br>тулаем территориаль продукт күләме;<br>сәнәгать продукциясе җитештерүе;<br>хезмәт хакы фонды (шул исәптән җирлекләр буенча), узган ел дәрәҗәсенә карата динамика;<br>оешмалар хезмәткәрләренең уртача исемлек саны, узган ел дәрәҗәсенә карата динамика;<br>уртача хезмәт хакы (шул исәптән җирлекләр буенча), узган ел дәрәҗәсенә карата динамика;<br>ваклап сату әйләнеше, узган ел дәрәҗәсенә карата динамика | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы | 2023 елның 5 июле | Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы |
| 5. | Нигезләүләр һәм аңлатма язуы белән 2024 – 2026 елларга Татарстан Республикасы икътисады | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | секторларын үстерү фаразының төп күрсәткечләре: | | | |
| 5.1. | Тәяп җибәрелгән продукция (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) күләме, сәнәгать җитештерүе индексы; ведомство буйсынуындагы оешмалар яктылыгында сәнәгать продукциясенең төп төрләрен җитештерү | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министр-лыгы | 2023 елның 23 августы | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Система |
| 5.1.1. | Тәяп җибәрелгән продукция (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) күләме, сәнәгать җитештерүе индексы; ведомство буйсынуындагы оешмалар яктылыгында сәнәгать продукциясенең төп төрләрен җитештерү (1.2 пунктта билгеләнгән тәртип нигезендә) | Татарстан Республикасы Төзе-леш, архитектура һәм то-рак-коммуналь хуҗалык ми-нистрлыгы, Татарстан Респуб-ликасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Та-тарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологи-яләре һәм элемтә министр-лыгы, Татарстан Республикасы Экология һәм табигать бай-лыклары министрлыгы | 2023 елның 15 августы | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә ми-нистрлыгы, Система |
| 5.2. | Ваклап сату әйләнеше, узган ел дәрәҗәсенә карата динамика;<br>җәмәгать туклануы әйләнеше, узган ел дәрәҗәсенә карата динамика | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министр-лыгы | 2023 елның 23 августы | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Система |
| 5.3. | Тышкы икътисадый эшчәнлек:<br>товарлар экспорты;<br>товарлар импорты | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министр-лыгы | 2023 елның 23 августы | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Система |
| 5.4. | Авыл хуҗалыгы продукциясе күләме, узган ел дәрәҗәсенә карата динамика;<br>авыл хуҗалыгы продукциясенең һәм агросәнәгать комплексында эшкәртү сәнәгатенең төп төрләрен җитештерү | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек ми-нистрлыгы | 2023 елның 23 августы | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Система |
| 5.5. | «Төзелеш» эшчәнлек төре буенча башкарылган эшләр күләме, узган ел дәрәҗәсенә карата динами-ка; | Татарстан Республикасы Төзе-леш, архитектура һәм то-рак-коммуналь хуҗалык ми- | 2023 елның 23 августы | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Система |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | барлык финанслау чыганаклары исәбеннән, шул исәптән социаль ипотека программасы буенча торак йортларны файдалануга тапшыру;<br>халыкны торакның гомуми мәйданы белән тәэмин итү (халыкның җан башына исәпләгәндә) | нистрлыгы | | |
| 5.6. | Теркәлгән эшсезләр саны (чор ахырына);<br>теркәлгән эшсезлек дәрәҗәсе (чор ахырына) | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | 2023 елның 23 августы | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Система |
| 5.7. | 2024 – 2026 елларга ведомство буйсынуындагы оешмалар эшчәнлегенең төп күрсәткечләренең төгәлләштерелгән фаразы | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы | 2023 елның 23 августы | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Система |
| 6. | Татарстан Республикасы Рәисенең Бюджет юлламасы проектына материаллар, шул исәптән:<br>2023 елның үткән чоры өчен Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү буенча якынча йомгаклар һәм 2023 ел өчен социаль-икътисадый үсеш буенча көтелә торган йомгаклар;<br>2024 – 2026 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү фаразы | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы | 2023 елның 11 сентябре | Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 7. | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты утырышы өчен 2024 – 2026 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү фаразы һәм 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты фаразы турында материаллар | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы | сентябрь, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының эш планы нигезендә | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты |
| 8. | 2023 елда Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү буенча төп күрсәткечләрне бәяләү | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | 2023 елның 22 декабре | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Система |
| 9. | Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү фаразын эшләү өчен кирәкле статистика мәгълүматы | Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы (килешү буенча) | ел дәвамында | республика башкарма хакимият органнары, муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары (килешү буенча), Система |

---